ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм «Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенә (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 16 пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«16) махсус инвестиция контрактында каралган, капитал салулар күләме кимендә 50 миллиард сум булган инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен яңа булдырылган яисә сатып алынган һәм махсус инвестиция контрактын имзалау елына кадәрге календарь елның 1 числосыннан иртәрәк булмаган вакытта исәпкә алынган мөлкәткә карата сәнәгать сәясәте өлкәсендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән федераль башкарма хакимият органы яисә «Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» 2014 елның 31 декабрендәге 488-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә сәнәгать тармакларында махсус инвестиция контрактларын төзүгә Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән

башка федераль башкарма хакимият органы аша эш итүче Россия Федерациясе белән бергә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә аның тарафыннан «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 2016 елның 21 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы аша эш итүче Татарстан Республикасы бер як буларак билгеләнгән махсус инвестиция контрактларында катнашучы, җөйсез корыч торбалар җитештерүче оешмалар. Ташлама, күрсәтелгән мөлкәт исәпкә алынган айдан соң килүче айның 1 числосыннан башлап, әмма махсус инвестиция контракты төзелгән айның 1 числосыннан иртәрәк түгел, махсус инвестиция контракты гамәлдә булу срогына, ләкин иң күбе 10 елга бирелә.».

**2 статья**

«Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2017 елның 2 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 94 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

«$2^1$. Татарстан Республикасы территориясендә капитал салулар күләме кимендә 50 миллиард сум булган җөйсез корыч торбалар җитештерү буенча инвестиция проектын гамәлгә ашыручы, махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле оешмалар табышына салым буенча салым ставкасы 0 процент күләмендә билгеләнә.»;

2) 3 өлештә «1 һәм 2 өлешләрендә» сүзләрен «1, 2 һәм $2^1$ өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 26 июль
№ 62-ТРЗ